СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

12 ФЕВРАЛЬ, 1997 ел. ЧӘРШӘМБЕ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 16 (8028) | Бәясе билгеләнгәнчә.

## Игътибар: яңа оешма

## ГАЗЛЫ БУЛЫР ӨЧЕН

***Аның тулы исеме - «Газпромстрой» берләшмәсенең Норлат төзү - монтаж участогы. Бу яңа оешма быелның 1 гыйнварыннан гамәлдә. Ул нинди максатта оештырылган, нинди бурычларны хәл итәчәк - участок начальнигы Г.Н.БИКИНЕЕВ белән әңгәмәбез шул хакта.***

- Участок район хакимияте башлыгы инициативасы белән районда газлаштыру эшен тизләтү максатында оештырылды. Бу - газүткәргечләрне монтажлау белән шөгыльләнәчәк оешма, ул шулай ук котельнялар, АВМнарны газлаштыруны башкарачак. Участок нигездә авылларны һәм шәһәрнең көньяк өлешен табигый газга тоташтыруга йөз тота. Тагы да төгәлрәк әйтсәк, быел участок Әмзә һәм Богдашкино авылларына газүткәргеч сузып, зәңгәр ягулык бирергә әзерләячәк. Шәһәрнең Көньяк өлешендә Киров урамыннан башлап Молодежная урамына кадәр, Южная, Куйбышев урамнарын кертеп шәхси йортларда эш алып барачакбыз.

**- Григорий Николаевич, оешмагыз зур түгел бугай әле?**

- Иң мөһиме - штаттагы 12 газ һәм электр белән эретеп ябыштыручының, слесарьларның һәрберсе - әзерлекле белгеч. Эретеп ябыштыручыларыбызның 10сы корыч, 2 се полиэтилен торбалар белән эшләүгә махсуслашканнар. Сүз уңаеннан, полиэтилен торбалар белән эшләүгә йөз тотуыбыз тикмәгә түгел. Ул бердән, арзанрак, икенчедән, мәшәкате азрак, өченчедән, аны файдалану срогы да озаграк. Без аны поселок эчендәге газүткәргечләрдә районда беренче тапкыр кулланачакбыз.

**- Шәһәрлеләрне көньяк микрорайонда башкарасы эшләрегез дә кызыксындырадыр дип уйлыйбыз.**

- Район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллин ветераннар белән очрашуда быел әлеге микрорайонда 500 ләп йорт газлаштырылачак, дигән иде. Безнең участок өчен бу хәл итәрлек бурыч дип уйлыйм. Сүз уңаеннан, анда яшәүчеләрнең дә моңа алдан әзерләнүләрен сорар идек (бу финанс мәсьәләсенә кагыла). Якын елларда шәхси кулланучылар өчен газга түләү предприятиеләр түләве дәрәҗәсенә күтәреләчәк, шунлыктан бүгеннән газ хисаплагычлары (счетчиклар) булдыру хәстәрен дә күрсеннәр иде. Анысын бездән үк ала алалар, ул чагыштырмача арзан.

**- Григорий Николаевич, аңлавымча, яңа оешма эшкә керешеп килә инде.**

- Әйе, 14 гыйнвардан без Лев Толстой урамыннан Линейная урамына кадәр шәхси йортларда эш башладык, эчке монтаж эшләре алып барабыз, берочтан Калинин, Димитров урамнарына газүткәргечләр сузу белән дә мәшгульбез.

**Әңгәмәдәш - С.ХӘЙРУЛЛИНА.**

## Хезмәтләре белән мактаулылар



Миндубаевлар гаиләсеннән үрнәк тә, киңәш тә, акыл да алырга мөмкин. Әкълимә белән Җәүдәтнең үзара ихтирамлы мөнәсәбәте, эш сөючәнлеге авылдашлары арасында күптәннән өлге итеп сөйләнә. Тату, акыллы гаиләдә үскән балалар да җирдә нык торырлык, кешелекле, булдыклы булып житештеләр. Ә гаилә башлыклары таза, нык тормышлы гаилә йөген һаман да үзара килешеп, аңлашып тарталар, хуҗалык эшендә дә элеккечә үк алдынгылар сафында баралар. Әни кеше Әкълимә озак еллар сыер савучы булып эшләсә, гаилә башлыгы Җәүдәт I класслы механизатор. Аның ЮМЗ - 6сына хуҗалыкта бер дә эш бетеп тормый. Хәзер дә Җәүдәт Касыймович такта ярдыру цехында агач тарттыру белән мәшгуль. Һәрвакыттагыча, эшен җиренә җиткереп, бер дигән итеп башкара ул.

**Рәсемдә: «Татарстан» КХАсы механизаторы Җ.К.Миндубаев. Н. АЗИЗОВ фотосы.**

**Рәсми хроника**

## Совхозда - яңа директор

«Төрнәс» совхозы директоры вазифаларын башкаручы А.В.Титов ул эштән шәхси гаризасы буенча азат ителде.

Директор итеп элек «Сөлчә» хуҗалыгы директоры булып эшләгән Рәфыйк Габбас улы Шәйдуллин билгеләнде.

## АВЫЛ ТАРИХЫНДА БЕРЕНЧЕ МӘЧЕТ

Төрнәстә беркайчан да мәчетләрне сүтмәгәннәр, чөнки... авылда мәчет булмаган. Чиркәү булган булуын, әмма «халыкка агу булганлыгы» өчен аның нинди язмышка дучар ителгәнлеге мәгълүм. Иҗтимагый - сәяси климат җылына башлауның беренче билгеләре күренү белән, чиркәүне яңадан торгыздылар һәм ул хәзер, элеккеге хәленә үк кайтып җитмәсә дә, Аллага һәм кешеләргә хезмәт итә. Инде менә авылда карап торышка тыйнак кына, әмма күккә үрелгән горур манарасы очында ай ялтырап торган мәчет тә калкып чыкты. Анысы да Ходайга һәм кешеләргә хезмәт итәр. Димәк, күңелең дингә, иманга тартыла икән, аларның олугъ чагылышы булган чиркәүне дә, мәчетне дә булдырырга беркайчан да соң түгел. Ник дисәң, дин юлына илтә торган сукмак яхшылык, изгелек кебек, кешенең йөрәге аша үтә, аңа таба бер адым гына атларга кирәк, диелә бит изге китапларда...

8 февральдә Төрнәс авылында мәчет ачу тантанасында чакта нәкъ менә шул турыда уйладым. Күп халык җыелган иде мәчет янына. Чыннан да, кешеләр мондый вакыйганы бәйрәм итеп кабул итәләр шул, аңа алдан ук әзерләнәләр, туганнарын, якташларын чакыралар. Ә монда әле тагын махсус автобус белән Норлаттан мәчет картларын да алып килделәр. Кыскасы, Төрнәс авылы өчен әһәмиятле вакыйга игътибардан читтә калмады. Өстәвенә, иртәдән үк көне дә элеккеге көнге бураннан соң матур, кояшлы иде.

Тантананы Коръән сүрәсе укып Норлатның көньяк мәчете имам - хатыйбы, Октябрь һәм Аксубай мөселманнарының вәкиллекле дини җитәкчесе Зәкиулла хәзрәт Әхмәтшин ачты. Ул халыкны сафлыкка, пәйгамбәребез Мөхәммәтнең әйткәннәренә тугъры булып, төрле милләт һәм дин халыкларын бердәмлектә һәм татулыкта яшәргә чакырды. Аннан соң сүз алучы - мәчет төзетүнең инициаторларыннан һәм ул эштә актив катнашучыларның берсе Хәйдәр Минһаҗ улы Ярмөхәммәтов тантанага җыелган халыкка бүген зурлап килгәннәре, барлык авылдашларына, шушы авылдан чыккан якташларына мәчетне торгызуда күрсәткән ярдәмнәре өчен рәхмәт белдерде. Район хакимияте башлыгының беренче урынбасары Ю.В.Терентьев, райпо рәисе М.С.Моратов төрнәслеләргә изге теләкләрен җиткерделәр, Норлатның шикәрчеләр бистәсендә төзелүче мәчетнең имам - хатыйбы Вәгыйзь хәзрәт Кадыйров та яхшы сүзен әйтте.

Тантана җыелган халыкның мәчеткә китергән күпсанлы сәдакаларына дога кылу белән тәмамланды. Халык авылга иман иңдергән изге йортны җиткезүчеләргә ихлас күңелдән рәхмәт белдерде.

**Д.ТӘМАЕВА.**

*Номерга хат*

## Бик сөендек

Кадерле редакция! Норлат - Тумба автобус маршруты ачылганга сөенеп бетә алмыйбыз. Шуңа да без, Тумба халкы район хакимиятенә, шәхсән Ф.С.Сибагатуллинга безнең турыда зур кайгыртучанлык күрсәтүләре өчен ихлас рәхмәтебезне газета аша җиткерергә телибез. Шатлыгыбызның чиге юк, ник дисәң дә гомерлек хыялыбыз чынга ашты бит. Юкса элек берәр яры барасыбыз булса язмышыбызга сукрана - сукрана пычрак ерып, узгынчы машиналарга кул күтәреп гомеребез узды. Шуңа да безнең турында кайгырткан өчен тагын бер тапкыр рәхмәт әйтәбез. Үзегезгә дә тазалык - саулык, уңышлар телибез, Фатыйх Сәүбәнович!

**Ю.ГАЙНУЛЛИН. Тумба поселогы.**

## «Татарстан өченче меңъеллыкта»

«Үткән мирасыбыз байлыкларын үзләштереп, киләчәккә лаеклы адым ясарга!»- республика мәктәп укучыларына исәпләнгән комплекслы социологик - инновацион бу уенның девизы шундый. Мәктәп укучыларының сәләтен ачыклау, аларның иҗади потенциалын ачу һәм үстерү өчен оптималь шартлар булдыру - уенның педагогик идеясе исә шулардан гыйбарәт.

Безнең районның яшь варислары да «Татарстан өченче меңъеллыкта» дип аталган бу уенга актив кушылды. Аның беренче этабы узган елның ноябрь аенда балалар - яшүсмерләр үзәгендә үтте. Уенчыклар күргәзмәсе, яшь эзтабарлар тарафыннан ясалган әйберләр, яшь иҗатчы альбомнары, рәсемнәр, фоторәсемнәр уен йомгакларын тасвирлаучы әйберләр булдылар. Бу чараларда Урта Камышлы, Чулпан, Бикүле, Мамык һәм башка урта мәктәпләр укучылары аеруча актив катнаштылар. Ә иң яхшы дип табылган эшләр февральдә үтәчәк республика конкурсында катнашу хокукын яуладылар.

Хәзер районның яшь варислары «Лего» конструкцияләре конкурсында катнашалар. Балалар - яшүсмерләр үзәге районның барлык балаларын, техник түгәрәкләргә йөрүчеләрне «Синең дустың - Лего» халыкара конкурсында катнашырга чакыра.

Ашыгыгыз! Конструкцияләрегезне безнең үзәккә 14 февральгә кадәр җибәрү зарури.

М.ГИНЯЕВА.

## Алда - хәлиткеч бурычлар

**Инде хәбәр иткәнебезчә, «Комбайн» КХАсында терлекчелек мәсьәләләренә багышланган семинар - киңәшмәдә беренче кварталның беренче ае йомгакларына анализны район хакимияте башлыгының беренче урынбасары Ю.В.ТЕРЕНТЬЕВ ясады. Бүген газета укучыларыбызга шул чыгышны тәкъдим итәбез.**

Яңа елның беренче аенда районның терлекчелек тармагында эш күрсәткечләре үткән елның шул чоры белән чагыштырганда, гомумән алганда, әйбәт дияргә була. Аерым алганда, үрчем сизелерлек артты, маллар арасында үлем очраклары да кимеде, сөт җитештерү һәм дәүләткә сату күрсәткечләре дә шактый югары булды.

Сөт җитештерүгә килгәндә, дүрт хуҗалыктан кала барысы да аны былтыргы дәрәҗәдән арттырды. Әйтик, «Кондырча»да бер сыер башына уртача 216 килограммга, «Восход»та 137гә, Муса Җәлил исемендәге КХАда 84кә, Мичурин исемендәге КХАда 76 килограммга күбрәк сөт савылды. Нәтиҗәдә районда дәүләткә сөт сату буенча квартал планы 1 айда 41 процентка үтәлде. Бу үткән ел күрсәткече белән чагыштырганда 14 процентка артыграк. Бу җәһәттән Мичурин исемендәге (планы 99 процентка үтәлгән), «Кондырча» (89), «Рассвет» (68), «Татарстан (61), «Родина» (59), Хафизов исемендәге (55) һәм Муса Җәлил исемендәге (55), «Восход» ассоциацияләрендә ул аеруча югары. Ә менә «Алга» (19), Әлмәт (23), «Комбайн» (28), «Таң» (27) КХАларында дәүләткә сөт сату бик сүлпән бара.

Кайбер хуҗалыклар ит сату буенча квартал планын бер айда ук арттырып үтәргә өлгерделәр. Мәсәлән, «Восход» (157 процентка ), Заветы Ильича(149), «Чирмешән»(124), «Чишмә»(113), «Сөлчә» (111), Киекле (114), «Кондырча» (103) хуҗалыклары шундыйлардан. Район буенча да квартал планы 67 процентка үтәлгән. Ә менә «Заря» (план үтәлеше1,5 процент кына), «Дуслык» ярдәмче хуҗалыгы (3), «Правда »(3), «Төрнәс» (8), МСО ярдәмче хуҗалыгы (16), «Игенче» (22), «Мамык» (23) ассоциацияләрендә ит сату бик авыр бара. Алга таба да шундый темп саклanса, квартал ахырына күрсәткечләр куанырлык булырга өмет тә юк.

( Ахыры 2 нче биттә).

# Татарстан Республикасы халык депутатын сайлау буенча участок сайлау комиссияләрен оештыру турында

## халык депутатларының Октябрь район Советы президиумы карары

(Дәвамы. Башы 14 - 15 нче саннарда).

**537 нче Зирекле сайлау участогы**

**Комиссия рәисе** - Рафик Мортаза улы **ХӘМЗИН,** Зирекле мәдәният йорты директоры.

**Комиссия члennары:** Рузилә Әсхат кызы **Әхмәтова**, Әнисә Касыйм кызы **Әхмәтсәгыйрова -** Зирекле урта мәктәбе укытучылары, Ралия Гариф кызы **Фәссахова** - «Үрнәк» КХА бухгалтеры, Зөлфәт Хәмит улы **Хуҗиәхмәтов**, Алмаз Нәбиулла улы **Шәрәфетдинов -** Зирекле урта мәктәбе укытучылары, Гөлчәчәк Сәлих кызы **Шәрәфетдинова** - Зирекле урта мәктәбе укытучысы.

**538 нче Чулпан сайлау участогы**

**Комиссия рәисе** - Рәшит Галимҗан улы **МИРЗАҖАНОВ,** Чулпан урта мәктәбе укытучысы.

**Комиссия члennары:** Суфия Мөнир кызы **Әндәрҗанова** - Чулпан участок шифаханәсе шәфкать туташы, Алсу Сабир кызы **Вәлиәхмәтова** - Чулпан урта мәктәбе укытучысы, Миләүшә Зиннәтулла кызы **Гыйбадуллина** - «40 лет Победы» КФХА бухгалтеры, Алсу Мингата кызы **Мирзаҗанова,** Фәһимә Барый кызы **Нәбиуллина**, Расыйх Каим улы **Сәмигуллин** - Чулпан урта мәктәбе укытучылары, Николай Алексеевич **Тафеев** - Чулпан метеостанциясе начальнигы, Розалия Вәгыйзь кызы **Хәлимова** - «40 лет Победы» КФХА бухгалтеры.

**539 нчы Заречный сайлау участогы**

**Комиссия рәисе** - Зоя Васильевна **ЛЕБЕДЕВА,** Заречный фельдшер - акушерлык пункты санитаркасы.

**Комиссия члennары:** Николай Михайлович **Александров** - Октябрь урман хуҗалыгы профсоюз комитеты рәисе, Оксана Валерьевна **Грушева** - Заречный башлангыч мәктәбе укытучысы, Александр Иванович **Ерофеев** - Чулпан урман пункты эшчесе, Наталья Николаевна **Пашунина** - Чулпан урман пункты бухгалтеры, Юлия Васильевна **Светкина** - Октябрь урман хуҗалыгы склад мөдире, Юрий Александрович **Серов** - Октябрь урман хуҗалыгы хуҗалык мөдире.

**540 нчы Бутаиха сайлау участогы**

**Комиссия рәисе** Евгений Владимирович **САРАЙНОВ,** Бутаиха тулы булмаган урта мәктәбе укытучысы.

**Комиссия члennары:** Марс Минәхәт улы **Закиров** - Бутаиха агач эшкәртү пункты мастеры, Әлфинур Исмәгыйль кызы **Кәлимуллина** - Бутаиха агач эшкәртү пункты бухгалтеры, Фәрит Зәкиулла улы **Мәсгутов** - Бутаиха агач эшкәртү пункты начальнигы, Оксана Геннадьевна **Сарайнова** - Бутаиха тулы булмаган урта мәктәбе укытучысы, Любовь Ильинична **Холкина** - Бутаиха агач эшкәртү пункты баш бухгалтеры, Сергей Николаевич **Холкин** - Бутаиха агач эшкәртү пункты рамчысы.

**541 нче Андреевка сайлау участогы**

**Комиссия рәисе** - Алексей Николаевич **ТАРАСОВ,** «Восход» КХА газ слесаре.

**Комиссия члennары:** Виталий Иванович **Абрамов** - «Восход» КХА трактор бригадасы бригадиры, Галина Аркадьевна **Абрамова** - «Восход» КХА кассиры, Татьяна Петровна **Абрамова** - балалар бакчасы мөдире, Нина Ивановна **Иванова** - китапханә мөдире, Виталий Аркадьевич **Иванов** - «Восход» КХА шоферы, Любовь Петровна **Колесникова** - җирле үзидарә Советы секретаре, Валентина Петровна **Лаврентьева** - җирле үзидарә Советы бухгалтеры, Сергей Михайлович **Сергеев** - «Восход» КХА тракторчысы.

**542 нче Богдашкино сайлау участогы**

**Комиссия рәисе** - Надежда Николаевна **АЛЕКСАШКИНА,** Богдашкино урта мәктәбе укытучысы.

**Комиссия члennары:** Вера Владимировна **Аввакумова** - Богдашкино урта мәктәбе укытучысы, Владимир Михайлович **Аввакумов** - механизатор, Татьяна Николаевна **Жукова** - китапханәче, Геннадий Яковлевич **Колесников** - участок ветеринария табибы, Галина Юрьевна **Совкова** - җирле үзидарә Советы секретаре, Алевтина Владимировна **Совкова** - Госстрах агенты.

**543 нче Егоркино сайлау участогы**

**Комиссия рәисе** - Юрий Валерьевич **ПОРТНОВ,** Кузнецов исемендәге КХА шоферы.

**Комиссия члennары -** Юрий Петрович **Ванеркин** - Кузнецов исемендәге КХА бригадир ярдәмчесе, Николай Евгеньевич **Кулагин** - Кузнецов исемендәге КХА тимерчесе, Антонина Владимировна **Мандрейкина** - мәктәп тәрбиячесе, Антонина Маркеловна **Михеева** - шәфкать туташы, Владимир Петрович **Мандрейкин** - Кузнецов исемендәге КХА звено җитәкчесе, Лариса Илларионовна **Павлова** - колхозчы, Анатолий Викторович **Трофимов** - Егоркино урта мәктәбе укытучысы, Светлана Васильевна **Павлова** - колхозчы.

**544 нче Каравыл Тавы сайлау участогы**

**Комиссия рәисе** - Владимир Иванович **БОРИСОВ,** Каравыл Тавы мәктәбе укытучысы.

**Комиссия члennары:** Иван Егорович **Башмаков** - төзүче, Геннадий Александрович **Волков** - клуб мөдире, Надежда Григорьевна **Волкова** - бухгалтер, Галина Алексеевна Игнатьева - укытучы, Надежда Николаевна **Казачкова** - Кузнецов исемендәге КХА эшчесе, Геннадий Михайлович **Корнилов** - Кузнецов исемендәге КХА члены, Галина Петровна **Краснова** - кирпеч заводы эшчесе, Нина Семеновна **Сандимирова** - Каравыл Тавы мәктәбе укытучысы.

**545 нче Урта Камышлы сайлау участогы**

**Комиссия рәисе** - Надежда Аркадьевна **БАЙМЯШКИНА,** Урта Камышлы җирле үзидарә Советы баш бухгалтеры.

**Комиссия члennары:** Светлана Владимировна **Андреева** - Урта Камышлы балалар бакчасы мөдире, Юрий Сергеевич **Вурмандеев** - Мичурин исемендәге КХА умартачысы, Николай Сергеевич **Григорьев** - Мичурин исемендәге КХА тракторчысы, Анатолий Петрович **Ефимов** - Мичурин исемендәге КХА бригадирының техника буенча ярдәмчесе, Тамара Ильинична **Картузова,** Урта Камышлы урта мәктәбе укытучысы, Татьяна Финкадьевна **Петрова** - Урта Камышлы авылы китапханәчесе.

**546 нчы Вишневая Поляна сайлау участогы**

**Комиссия рәисе** - Гөлсинә Гарәфетдин кызы **МИФТАХЕТДИНОВА,** Мичурин исемендәге КХА экономисты.

**Комиссия члennары:** Людмила Михайловна **Блинова** - Мичурин исемендәге КХА бухгалтеры, Елена Алексеевна **Еремеева** - Мичурин исемендәге КХА кассиры, Наталья Васильевна **Илларионова** - Мичурин исемендәге КХА бухгалтеры, Валентин Васильевич **Маланьин** - Мичурин исемендәге КХА агрономы, Федор Николаевич **Миронов** - Вишневая Поляна урта мәктәбе укытучысы, Алексей Арсентьевич **Ухванов** - Мичурин исемендәге КХА терлекчесе.

**547 нче Киекле сайлау участогы**

**Комиссия рәисе** - Йосыф Хатыйп улы **САДЫЙКОВ**, мәктәп директоры.

**Комиссия члennары:** Клара Мифтах кызы **Гафиятуллина** - кассир, Гөлчәчәк Шәйхи кызы **Гыйматова** - укытучы, Әнвәр Сәетгәрәй улы **Исламов** - авыл мәдәният йорты директоры, Нурбисал Кашаф кызы **Сафина** - бухгалтер, Рафаэль Нәҗип улы **Сиражетдинов** - шофер, Роза Әхмәтвәли кызы **Яруллина** - кассир.

**548 нче Кизләү сайлау участогы**

**Комиссия рәисе** - Хәлил Сәлихҗан улы **КУРАМШИН,** Кизләү урта мәктәбе укытучысы.

**Комиссия члennары:** Фәнис Йолдыз улы **Әхмәтов** - шофер, Фәридә Юныс кызы **Вафина** - авыл мәдәният йорты директоры, Рәис Минвәли улы **Ганиев** - укытучы, Әнисә Хафиз кызы **Гыймалетдинова** - бухгалтер, Гөлүсә Вахит кызы **Нугаева** - балалар бакчасы мөдире, Флюра Хатыйп кызы **Рәхмәтуллина** - укытучы.

**549 нчы Иске Чаллы сайлау участогы**

**Комиссия рәисе** - Любовь Ильинична **ПОМЕЛОВА,** Синдряков исемендәге КХА техник - төзүчесе.

**Комиссия члennары:** Лидия Леонидовна **Айкина** - Иске Чаллы авылы китапханәчесе, Валентина Ильинична **Бикинеева** - Иске Чаллы шифаханәсе шәфкать туташы, Рәис Миннәфис улы **Вафин** - Синдряков исемендәге КХА газовигы, Зиннур Әхтәм улы **Нургалиев** - клуб мөдире, Николай Викторович **Нилов** - Синдряков исемендәге КХА инженеры, Наталия Валентиновна **Фомина** - Иске Чаллы җирле үзидарә Советы бухгалтеры.

**550 нче Түбән Чаллы сайлау участогы**

**Комиссия рәисе** - Иван Борисович **ЯКОВЛЕВ,** урта мәктәп директоры.

**Комиссия члennары:** Павел Иванович **Варламов** - Синдряков исемендәге КХА механигы, Галина Петровна **Васильева** - урта мәктәп директоры, Марина Владимировна **Герасимова** - урта мәктәп укытучысы, Валерий Николаевич **Леонтьев** - Синдряков исемендәге КХА шоферы, Наталья Алексеевна **Маркова** - Синдряков исемендәге КХА секретаре, Любовь Николаевна **Семенова** - Түбән Чаллы җирле үзидарә Советы баш бухгалтеры.

**551 нче Төрнәс сайлау участогы**

**Комиссия рәисе** - Владимир Семенович **ЕНИЛИН**, баш ветеринария табибы.

**Комиссия члennары:** Любовь Григорьевна **Малышева** - Төрнәс җирле үзидарә Советы секретаре, Людмила Александровна **Петрова** - Төрнәс җирле үзидарә Советы кассиры, Дмитрий Алексеевич **Помендеев** - газ хуҗалыгы буенча инженер, Фатыйма Фәрит кызы **Садыйкова** - урта мәктәп укытучысы, Александр Михайлович **Сазонов** - баш инженер, Любовь Петровна **Сенькина** - урта мәктәп укытучысы.

**552 нче Мамык сайлау участогы**

**Комиссия рәисе** - Виктор Геннадьевич **ШУХРОВ**, Зүзәй нефть промыселы эшчесе.

**Комиссия члennары:** Людмила Васильевна **Алексеева** - «Агрохимия» АООТ бухгалтеры, Лидия Николаевна **Золина** - Мамык китапханәсе мөдире, Галина Николаевна **Кандинова** - Мамык авылы китапханәчесе, Ольга Александровна **Прохорова** - Мамык кирпеч заводы бухгалтеры, Сергей Дмитриевич **Прокудин** - «Сөлчә» ярдәмче хуҗалыгы эшчесе, Зөһрә Таваровна **Раджанова** - Мамык участок шифаханәсе санитаркасы.

**553 нче Сәләнгеш сайлау участогы**

**Комиссия рәисе** - Любовь Анатольевна **ГАЛИЦЫНА,** Сәләнгеш урта мәктәбе директоры.

**Комиссия члennары:** Татьяна Александровна **Белогубова** - «Заветы Ильича» КХА бухгалтеры, Владимир Геннадьевич **Корнеев** - авыл мәдәният йорты директоры, Светлана Геннадьевна **Макарова** - Сәләнгеш урта мәктәбе лаборанты, Александр Николаевич **Пинин** - «Заветы Ильича» КХА хуҗалык мөдире, Ольга Анатольевна **Сарайнова** - саклык кассасы контролеры, Ирина Аркадьевна **Самойлова** - балалар бакчасы мөдире.

**554 нче Кычытканлы сайлау участогы**

**Комиссия рәисе** - Ринат Нәкыйф улы **МОГЫЙНОВ**, авыл мәдәният йорты директоры.

**Комиссия члennары:** Әминә Нургаяз кызы **Әхмәтвәлиева** - урта мәктәп укытучысы, Гөлсинә Әсхать кызы **Гәрәева** - фельдшер - акушерлык пункты мөдире, Әхәт Нәбиулла улы **Галиуллин** - «Татарстан» КХА агрономы, Җәмилә Исхак кызы **Гыйлемшина** - «Татарстан» КХА кассиры, Дания Рамазан кызы **Мансурова** - китапханәче, Җәмилә Хаварис кызы **Нургалиева** - җирле үзидарә Советы бухгалтеры, Ринат Әхәт улы **Нуруллин** - «Татарстан» КХА механизаторы, Эльмира Әнвәр кызы **Сабирова** - Кычытканлы урта мәктәбе укытучысы.

**555 нче Яңа Әмзә сайлау участогы**

**Комиссия рәисе** - Әнвәр Галим улы **ФӘССАХОВ**, Яңа Әмзә урта мәктәбе укытучысы.

**Комиссия члennары:** Җәүдәт Хөҗҗәт улы **Зәйниев** - «Комбайн» КХА хуҗалык мөдире, Фәрит Фоат улы **Нәбиуллин** - Яңа Әмзә урта мәктәбе укытучысы, Айнур Госман кызы **Сафина** - Яңа Әмзә җирле үзидарә Советы секретаре, Рәис Харис улы **Фәссахов** - мәдәният йортының сәнгать җитәкчесе, Гөлүсә Габдулла кызы **Фәссахова** - «Комбайн» КХА экономисты, Наилә Наил кызы **Фәтхетдинова** - китапханәче.

**556 нчы Иске Әмзә сайлау участогы**

**Комиссия рәисе** - Гайфетдин Фәсхетдин улы **СӘЙФЕТДИНОВ,** Яңа Әмзә урта мәктәбе укытучысы.

**Комиссия члennары:** Әүхәт Әсхать улы **Галимов** - профком рәисе, Гүзәл Галимҗан кызы **Мусина** - Иске Әмзә фельдшерлык пункты мөдире, Сәкинә Гайфетдин кызы **Сәгъдиева** - китапханәче, Рушания Рифкать кызы **Сафина** - Иске Әмзә башлангыч мәктәбе укытучысы, Кадрия Шамил кызы **Шәйдуллина** - бухгалтер - кассир, Әнвәр Әһлиулла улы **Шәйдуллин** - Иске Әмзә авылы мәдәният йорты мөдире.

**557 нче Кызыл Юл сайлау участогы**

Комиссия рәисе - Шамил Фазлый улы **ГЫЙЗӘТУЛЛИН**, лесничий урынбасары.

**Комиссия члennары:** Мария Ильинична **Белицкая** - Чурабатыр башлангыч мәктәбе мөдире, Алевтина Анатольевна **Котова** - Кызыл Юл авыл клубы мөдире, Рәүф Илали улы **Нуретдинов** - шофер, Гөлчәчәк Тәлгать кызы **Нуретдинова** - Кызыл Юл башлангыч мәктәбе мөдире, Вера Павловна **Щекачева** - Кызыл Юл башлангыч мәктәбе укытучысы, Валентина Александровна **Курочкина** - клуб мөдире.

**558 нче Иске Әлмәт сайлау участогы**

**Комиссия рәисе** - Җәүдәт Габбас улы **ХӘЙРУЛЛИН,** Әлмәт КХА экономисты.

**Комиссия члennары:** Рәфис Наил улы **Вәлиев** - терлекчелек буенча механик, Сания Газизҗан кызы **Вафина** - бухгалтер, Суфия Минсәлим кызы **Гыйләева** - Госстрах агенты, Мансур Марс улы **Нәбиуллин** - укытучы, Гүзәл Марс кызы **Нәбиуллина** - мәктәпнең уку - укыту эшләре мөдире, Зәйтүнә Шәйхетдин кызы **Тахиятуллина** - китапханәче, Вәгыйзь Шәйхетдин улы **Шәрапов** - клуб мөдире, Владимир Анатольевич **Шилов** - баш агроном.

(Ахыры 4 нче биттә).

